**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**«Бәркәтә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге составына керүче
Бәркәтә авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**26 октябрь 2023 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 25 октябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде түбәндәге сораулар буенча: «2023 елда Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 600 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

1. «Шушма» елгасы аша җәяүлеләр кичү юлын төзү (култыксаларны (перила) ремонтлау, такталар урнаштыру);
2. Бәркәтә торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
3. Бәркәтә торак пунктында стеланы төзү, проект-смета документациясе өчен түләү;
4. Җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, триммерлар, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 480 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 245 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 245 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге составына керүче Бәркәтә торак пунктында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 600 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- «Шушма» елгасы аша җәяүлеләр кичү юлын төзү (култыксаларны (перила) ремонтлау, такталар урнаштыру);

- Бәркәтә торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Бәркәтә торак пунктында стела төзү, проект-смета документациясе өчен түләү;

- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, триммерлар, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Бәркәтә авылы, Ленин урамы, 76 а йорты. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче**
**Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы** **Р.М.Сибгатуллин**